



# МБУ ЦБС Рыбно-Слободского муниципального района.
# Уреевская сельская библиотека
# Филиал № 33







# Конкурс
# « Туристической тропой по родному краю»





# Туган авылым

Жир йозендэ авыллар куп
Тик минеке бер генэ
Ин гузэле,ин матуры
Туган авылым син генэ.

# Конкурсның максаты:

Районыбыз һәм  Бирдебәк авылы тарихын өйрәнү, бүгенгесен барлау, авылның истәлекле урыннарына, чишмәләргә экскурсиягә бару, мәктәп тарихын өйрәнү, данлыклы һөнәрчеләрен барлау , үз халкына,тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту яшәешенә битараф булмаска өйрәтү;

- **Бурыч**:  үз авылыңның тарихын,истәлекле урыннарын белү.

# Туган авылым - горурлыгым

Нәкъ Тукай абый язганча, тау башына салынгандыр безнең авыл, бер чишмә бар якын безнең авылга ул. Авылыбыз иң гүзәл авылларның берседер. Якында гына куе урман. Искиткеч авылымның табигате! Кышын бигрәк тә җәйге иртәләрне сагынасын. Талгын гына салкын җил исә, кояш нурлары тәрәзәдән күзне чагылдыра. Бар җиһанга кошлар җыры тарала. Нинди генә авазлар чыгармыйлар алар. Менә кәккүк тә нидер санап ала. Мондый күренеш белән бары тик урман буенда урнашкан авылларда яшәүчеләр генә таныштыр.Бары тик шушындый табигатьтә яшәүчеләр генә туган ягының кадерен белеп яшидер төсле.

# Туган җирем бер генә

Туган ягым,туган авылым,
Мин-синең газиз балаң.
Саф сулы чишмәләреңнән
Җаныма сихәт алам.



Сусавымны басар кебек
Туган як чишмәләре.
Җилләрнең дә иң назлысы
Шул яктан искәннәре.



Кадерледән дә кадерле
Туган үскән ил генә.
Чит – ят җирләр күп булса да,
Туган җирем бер генә.


Балык бистәсе районы
Бирдебәк авылы
Офыкларга карыйм сине сагынып,
Кызарып ла кояш батканда.

# БИРДЕБӘК АВЫЛЫ ҺӘМ БИРДЕБӘК ХАН ТУРЫНДА


«Бирдебәк авылы тау башындабер хан, Кала тау башында икенче хан була. Бирдебәк белән Кала тау башын биләүчеләр берсенең утын икенчесе күреп торганнар».


Риваятьләрдән күренгәнчә Бирдебәк авылы тавында Бирдебәк хан яшәгән ҺӘМ МОНДА борын заманда каты сугышлар да булып торган. Бармы сон, тарихта Бирдебәк дигән хан һәм ул кайчан яшәгән?

Тарихта татар ханнары арасында Җанибәк хан улы Бирдебәк хан булуы мәгълүм. Җанибәк 1357 елны авырып үлгәч, аның урынына улы Бирдебәк хан утыра. Ул 1359 елны үтерелгән.






Авылым күренеше.


Кояш иң беренче булып аксыл,
саргылт, кызгылт төсләрне
үзенә җыеп,
матур булып
безнең авылда чыга.
Мондый төс бары тик
минем туган ягыма гына хас.


Елга ага борма-борма
Аннан тауга борыла
Тау янында минем
авылым
Урман белэн орына


Кошлар сайрый тирәктә
Сыгылып үсә таллары,
Кайда йөрсәм дә йөрәктә
Авылымның таңнары.


# “Туган җирем, үскән җирем, гади генә бер авыл”.

Болыннарга чәчәкләрдән
Гөлләр генә тушәлгән
Тирәкләрдә сандугачлар
Быел тагын ишәйгән.



# Урман – табигать могҗизасы




.

# Авылым чишмәләре

Җир куеныннан көмеш балдаклар чыгарып ургылучы чишмәләр кемгә генә кадерле түгел икән?
 Безнең балачагыбыз да гүя шуннан башлана, яшел чирәмле чишмә юлы безне олы тормышка алып чыга.
Безнең авылыбыз да да чишмәләр бар. Аларның һәрберсенең үз тавышы, үз тарихы,үз моңы, үз аһәңе, үз агышы, үз юлы бар.”Бохар” чишмәсе”- югары һәм түбән оч урамнары халкын хәзер дә су белән тәэмин итеп торучы мул сулы чишмә. Чишмәләр үзләренә генә хас сихри моңга ия. Озак еллардан соң ерак җирләрдән кайткан кунаклар-чишмә янына төшеп утыруны тиеш дип саныйлар. Алар чишмә тавышын тыңлап, яңаклары буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен әкрен генә сөртеп, чишмә суында бит-кулларын юалар.



# Бохар чишмэсе

Буралы чишмə сулары
Гел шулай шаулап аксын.
Тыныч,матур тормышларда
Безгə яшəргə язсын.


Табигать матурлыгы


“БАКА” күле


Ерак тугел тирәсендә
Чишмә,күлләр әрәмә
Ак мамыктай каз урдәктәй
Сибелгәннәр чирәмгә


Менә кайда ул чын гүзәллек!


Төрле ел фасылында
табигать матурлыгы!

# Мәчет – изге урын











Берәүләр
белем бирә
балаларга,
Берәүләр
нигез сала
калаларга

Һәр төбәкнең бик матур кешеләре бар. Төскә биткә генә түгел, күркәм эшләре, тоткан кыйблалары белән киләчәк буыннарга үзләреннән тирән эз калдырган шәхесләр яши. Алар мактанып йөрмиләр, тыныч кына яши бирәләр.

# Урaман байлыклары






Авылдан мин , буразнадан,
Басу кырлар арасыннан.
Җан суы итеп эчәрлек
Саф  чишмәләр тарафыннан

# Алар даны мәңгелек!



# Халык хэтере мэнгелек

Бер кайтмасак, бер кайтырбыз дип китсәләр дә, күпме авылдашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада.



# Аларга мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт!




# Авылым китапханәсе




2012
ТАРИХИ - МӘДӘНИ МИРАСЫ ЕЛЫ
Ватаным Татарстан
Татарстан тарихы
27/09/2012 17:34


Открывая книгу –
Ребятам от зверят
Кече яшьтәге укучылар өчен китаплар
27/09/2012 17:23


Экстремизму-нет
Сохраните жизнь себе и близким
Телефоны экстренных служб:
Телефон доверия:291-20-02
МВД по РТ:02
Экстренный вызов с мобильного телефона :112, 012
МӨКЕРЛЕ ПЛАННАР ТОРМЫШКА АШМАС
ТЕРРОРИЗМ И ЭКСТРЕМИЗМ
ГЛАВНЫЕ УГРОЗЫ СОВРЕМЕННОГО МИРА
ЧТО ДЕЛАТЬ В ТОЛПЕ ПРИ ТЕРАКТЕ
27/09/2012 17:35


27/09/2012 17:22

# ЙОГАКЛАУ:

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә, без, яшь буын, туган ягыбызның киләчәге өчен җаваплы кешеләр. Туган төбәгебезенең тарихын җентекләп өйрәнеп, эш-гамәлләребезне аның табигатенә зыян китермәслек итеп оештырырга тиешбез.

Тормышыбызда нәфрәт уятырлык вакыйгалар очрап торса да, сокланып , яратып , горурланып сөйләрлек туган җиребез бар, табынырлык кешеләребез бар.

Кешелек дәвам итә. Әле бездән соң да, буыннан-буынга матур җырларыбыз, күркәм эшләребез күчеп барыр.

Көн артыннан көн туа. Кеше гомере аккан су кебек, искән җил кебек тиз генә үтеп тә китә.

Без дөньяда яшибез икән, үзебездән соң килгән буыннарга да аналарны олылау, туган җиребезне, туган телебезне, динебезне хөрмәт итү, табигатьне саклау кебек күркәм сыйфатларны, гореф-гадәтләрне яшь буынга түкми-чәчми тапшырырга, мирас итеп калдырырга тиешбез. Шулай булганда гына без сәламәт һәм бәхетле кешеләр булырбыз, бездән соң килгән буынга бай табигый мирас калдырырбыз.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

# Безгә кунакка килегез!



# Презентация

# Подготовлена библиотекарем Уреевской сельской библиотеки Валиуллиной Р

